# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**27 ноябрь 2021 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 27 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары (җыен) нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2021 елда Сәпәй авыл җирлегендә контейнер мәйданчыклары (контейнерлар, коймалар өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары төзү (нигез корылышы, коймалар) урнаштырганнан соң янга калган (экономияләнгән) 13 885 (унөч мең сигез йөз сиксән биш сум 69 тиен) сум гражданнарның үзара салым акчасын 2022 елда

- Сәпәй авыл җирлегендә җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне кипкән агачлардан һәм куаклардан (мәчет, авыл клубы, ФАП һәм балалар бакчасы территорияләрен) чистарту, территорияне механикалаштырылган чабу хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәтләре, территорияне яшелләндерү буенча чаралар уздыру өчен файдалану белән килешәсезме"?

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 523 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 377.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 377, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2021 елда Сәпәй авыл җирлегендә контейнер мәйданчыклары (контейнерлар, коймалар очен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары төзү (нигез корылышы, коймалар) урнаштырганнан соң янга калган (экономияләнгән) 13 885 (унөч мең сигез йөз сиксән биш сум 69 тиен) сум гражданнарның үзара салым акчасын 2022 елда

- Сәпәй авыл җирлегендә җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияне кипкән агачлардан һәм куаклардан (мәчет, авыл клубы, ФАП һәм балалар бакчасы территорияләрен) чистарту, территорияне механикалаштырылган

чабу хезмәтләре өчен түләү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, территорияне санитар чистарту хезмәтләре, территорияне яшелләндерү буенча чаралар уздыру өчен файдалану белән килешәсезме”?

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сәпәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Галиева